СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

24.07.2020 | с. Татарское Бурнашево | 77-353

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В. Бурукин мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советы, гамәлдәге кануннар үзгәрүгә бәйле рәвештә, җирлек Советы тарафыннан хупланып, Җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка игълан ителде, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырылды һәм җирлек халкы белән гавами тыңлауларда фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын узып «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнүен билгеләп үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44нче статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7нче статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставының 20, 86-88 статьялары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставына, 1нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставының яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советының
2020нче елның 24нче июлендәге
77-353нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 5нче статьясындагы 1нче пунктының 20нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итү»;

2. Уставның 30нчы статьясындагы 3нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл җирлеге Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен, айга алты эш көненнән дә ким булмаган чорда эш урынын (вазыйфаларын) саклау гарантияләнә»;

3. Уставның 33нче статьясындагы 1нче пунктының 24нче пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.
4. Уставның 50нче статьясындагы 1нче пунктының 3нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау өлкәсендә:

- муниципаль норматив хокукый актлар проектлары буенча гавами тыңлаулар, җәмәгать тыңлаулары оештыра һәм үткәрә;

- халыкка экологик хәл турында хәбәр итә, тиешле органнарга предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турындагы законнарны бозучы гамәлләре турында хәбәр итә;

- Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яки федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә».

5. Уставның 50нче статьясындагы 1нче пунктының 7нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- җирлек территориясен төзекләндерү буенча эшчәнлекне оештыра, җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота;

- адресация объектларына адресларны бирә, адресларны үзгәртә, юкка чыгара, урам - юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәрен бирә, мондый атамаларны үзгәртә, юкка чыгара, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыра»;

6. Уставның 50нче статьясындагы 2нче пунктының 13нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда чаралар оештыра»;

7. 50нче статьяның 2нче пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992нче елның 7нче февралендәге 2300-1нче номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;

8. Уставның 85нче статьясындагы 1нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, җирле бюджеттан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләр бирә торган хокукый актлар нигезләмәләрен, шулай ук муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин